| СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 14.11.2023 | с. Лебяжье | № 51 |

**Лебяжье авыл җирлеге Советының**
**16.11.2018 ел, №107 «Җир салымы турында»**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә һәм Алексеевск районы прокуратураысының 19.10.2023 елдан №02-08-01-2023 протестын карап чыгып

**Лебяжье авыл җирлеге җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебяжье авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, № 107 «Җир салымы турында» карарының 2пунктының 2 пунктчасы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-торак фонды һәм (яисә) торак - коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары тарафыннан биләнгән(торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Лебяжье авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Д.Ә.Гыйләҗев**

СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ